Хәмидуллина, Р. Мәктәп еллары күңел түрендә: [хатирәләр яңартып] / Р.Хәмидуллина // Яшел Үзән. – 2024. – 13 сентябрь.

# МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ КҮҢЕЛ ТҮРЕНДӘ



Олы тормыш юлыннан барганда берәү дә үткән елларына әйләнеп карамый калмый. Һәр кеше кайгы-хәсрәтсез, мәшәкатьсез балачагын, мәктәп елларын сагынып искә ала. Һәркемгә үзе укыган белем учагы, укытучылары, сыйныфташлары кадерле һәм якын.

Кайда соң, кайда, шау-гөр килешеп,
Уйнап, көлешеп укыган чаклар!

Мәктәп еллары – һәркемнең кабатланмас матур бер мизгеле. Күңел түрләренә мәңге җуелмас шатлыклар, онытылмас истәлекләр нәкъ менә шул чорда салына. Кыңгыраулы мәктәп сукмагыннан, зур тормыш юлына чыгып киткәнгә инде 45 ел вакыт үтеп киткән. Аздырмы бу, күптерме... әмма еллар узган, безнең чәчләргә дә чаллар төшкән, барыбыз да әби-бабай булган, саллы гына тормыш тәҗрибәсе туплаган.

Шушы елда Норлат урта мәктәбен тәмамлаганга 45 ел булды һәм шул уңайдан сабакташлар, чордашлар очраштык.

Без, Мулла Иле авылы егет-кызлары, Норлат мәктәбендә 9-10нчы сыйныфларны укыдык. Мәктәпкә балалар төрле авыллардан: Норлат, Тау Иле, Бакырчы, Күгәй, Күгеш, Айдар, Әрә, Татар Исламы, Мулла Иленнән җыелганнар иде. Мулла Иленнән генә дә 13 бала йөреп, белем алдык. 10нчы «А» да – 32, «Б» да 39 укучы иде. Барлыгы – 71. Бүгенге чор авыл мәктәпләрендәге укучылар белән чагыштырганда, бу – шаккатмалы саннар. Очрашуга ике класстан шуларның 22се генә килә алган. Арабызда укуны тәмамлаганнан бирле бер тапкыр да күрешмәгән, очрашмаган сабакташларыбыз да бар.

Бу очрашуга без ярты ел алдан әзерләнә башладык. Хәзерге чорның шунысы яхшы, кем белән телисең, шуның белән Ватсап, социаль челтәрләрдә вертуаль сөйләшүләр алып барырга мөмкин. Очрашуга Норлат мәктәбендә сигезенче сыйныфны тәмамлап, төрле уку йортларына укырга киткән чордашлар да килгән иде. Күрешү кичәсен чордашлар очрашуы диеп тә атап булыр иде. Мин үзем очрашуга, бик күп сабакташларым кебек, атлап түгел, күңелем белән очып бардым.

Очрашуыбыз июль аеның иң матур, иң кызу көннәренең берсендә булды. Мәктәп бинасы белән янәшәдә урнашкан мәдәният йортыннан яңгыраган көйләр безнең күңелләргә бәйрәм оеткыларын салды.

Миңа кадәр мәктәп янына өч машина килеп өлгергән. Елмаюлы карашым белән килүчеләрне каршылаучы егет-кызларны күзәтәм, яннарына килеп, танырга тырышам. Мозаффаров Рәмисне (Норлаттан), Зарифуллин Фирдәвес, Ильясов Зөфәр (Күгештән), Ганиев Зөфәр (Мулла Иленнән), Нуруллина Флера, Минһаҗева Илсөяр (Тау Иленнән), Гыймадиев Гомәр, Гатауллин Равил, (Норлаттан), таныйм бит әле. Озак көттерми «А» сыйныфында укыган Норлат авылы кызлары Зыятдинова Фәридә, Гыйбадуллина Гөлнур, Кашапова Рәмзия, Мингалиева Саниялар, Күгәй авылыннан Зәбихуллина Резедә, Фәйзрахманова Роза, Татар Исламы авылыннан Заһидуллина Наилә килделәр. Сигезенче сыйныфтан соң киткән Гайнуллин Илшат, Шаһидуллин Рөстәм, Хөсниев Тәлгат, Гайнетдинова Резедә (Норлаттан), Җәләлов Әсхәт тә (Тау Иленнән) , сыйныфташларны сагынып, бик теләп очрашуга килгәннәр. Үсмер елларына кайткан кебек, күңелле итеп исәнләшеп, кочаклашып күрешкәннән соң, мәктәп бинасына үттек. 45 ел узмаган да кебек. Мәктәпкә алып менә торган шул ук баскыч. Без укыган мәктәпнең беренче катын балалар бакчасы итеп үзгәрткәннәр. Мәктәп янында шаулап утырган каен, нарат агачларын матур-матур чәчәкләр алыштырган. Янәшәдә яңа бина өлгерткәннәр. Шау-гөр килеп, әйтерсең, беренче сентябрь көне, яңа бинага үтәбез. Туктап, һәр мизгелне сурәткә төшереп калырга тырышабыз. Яңа мәктәпнең озын коридоры аша, безнең аяк тавышларын саклаган идәннәрне шыгырдатып, үзебез укыган мәктәпнең икенче катына узабыз. Мәктәпнең безгә кадерле өлешен саклаганнары өчен, җитәкчеләренә эчтән генә рәхмәтемне укыйм.

Хәзерге мәктәп белән якыннан таныштыруны инде күп еллар Норлат мәктәбендә укытучы булып эшләүче сабакташыбыз Гыйбадуллина Гөлнур бик теләп үзенә алды. Икенче каттагы коридорда мәктәп тарихына бәйле фотосурәтләр урын алган. Мәктәбебезне төрле елларда җитәкләгән җитәкчеләрнең, укытучыларыбызның фотосурәтләрен күрү күңелләрне җилкендерде. Төрле елларда мәктәпне тәмамлап, бүгенге көндә фән кандидатлары, галимнәр, гомумән, күренекле шәхесләр булып ирешкәннәрнең фотосурәтләрен күрү шатлык өстенә шатлык өстәде. Алар арасында безнең чыгарылыштан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, язучы Фирдәвес Зарифуллинның (Күгештән), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Роза Гыйззәтуллинаның (Мулла Иленнән) да булуы аеруча горурлык хисе уятты. Биредә Әфган, Чечня, бүгенге көн сугыш батырларының фотосурәтләре дә тиешле урын алган. Мәктәпнең бер бүлмәсендә туган якны өйрәнү музее оештырганнар. Музейның төрле экспонатларга бай булуы сокландырды. Без анда сугу станогы, сәгать, чигелгән сөлгеләр, сугылган паласлар белән янәшәдә глобус, парта, галстук, язу машинкасы, китаплар кебек бик күп экспонатлар белән очраштык.

Аннан, шау-гөр килеп, «Б» сыйныфының төп бүлмәсе булган химия кабинетына




үттек. Кабинет үзгәргән – парталар азайган, укытучы Гомәр абый Сабитов утырган зур өстәлне дә кечкенәсе алыштырган. Укытучы абыебыз инде юк, мәрхүм. Аннан чыгып, бөтен мәктәпне бер итеп, коридор буйлап, спорт залы ишекләренә кагылып китеп, алгебра кабинетына үтәбез. Алгебра, геометрия дәресләрен безгә Сәкинә Сафа кызы Ркиева укытты. «А» сыйныфының

житәкчесе дә ул булды. Сәкинә апабыз исән-сау, ләкин безнең белән очрашуга гына килә алмады.

Барыбыз да парта артларына тезелешеп утырдык. Гөлнур безгә ачык дәрес бирде. Мәктәпнең бүгенге көне белән таныштырып: «Бүгенге көндә мәктәбебезне яшь, житез, таләпчән, өлгер житәкче Зиннәтуллин Рамил Ринат улы житәкли. Мәктәптә барлыгы 17 класс, 312 укучы укый. Быел 9нчы сыйныфны – 40 укучы, 11не – 4 укучы тәмамладылар. ОГЭ, ЕГЭ ны да уңышлы билгеләренә тапшырдылар. Коллективта 30 укытучы дус, тату эшлибез», – диде. Шигъри күңелле Гөлнурыбыз мәктәп белән таныштыруын үзе язган шигырь юллары белән тәмамлады:

Бүген безне бергә җыйды мәктәп – оябыз,
Еллар аша җылылыгын аның тоябыз.
Балачак, яшьлек эзләрен кабат барларга
Очраштырсын, күрештерсен мәктәп алда да!

Шулай була күрсен, озын гомер, сәламәтлекләр биреп, сыйныфташлар белән киләчәктә дә очрашырга насыйп булсын диеп, мәктәп белән саубуллаштык. Ләкин таралышмадык, укытучыбыз Сәкинә апа яшәгән йортка юнәлдек. Алар 1970 елларда мәктәптә директор урынбасары булып эшләгән Мингалиева Рәфисә Шәрип кызы белән күрше булып яшиләр. Көннең матур, кояшлы, җылы булуыннан файдаланып, без аларның икесен дә урамга чакырдык. Сәкинә апабызның моннан 45 ел элек мәктәпне тәмамлаган укучыларының һәрберсен тануы безне сокландырды. Үзе дә күп еллар укытучы булып эшләгән (*хәзерге көндә лаеклы ялда)* сабакташыбыз Флера Нуруллина Сәкинә апага гына хас булган укыту алымнарын искә алып үтте. Үзенең эшендә дә ул алымнарны куллануын җиткереп, остаз-укытучысы Сәкинә апага рәхмәтен белдерде. Һәрберебез йөрәгебездән чыккан изге теләкләребезне, рәхмәтләребезне укытучы апаларыбыз – Сәкинә Сафа кызы белән Рәфисә Шәрип кызына ихластан җиткердек. Киләчәктә дә очрашып, күрешеп торырга насыйп булсын дигән теләкләрне ишеттердек. Очрашу истәлеге итеп зур чәчкә бәйләме белән бүләкләр тапшырдык.

Очрашуыбыз Норлат авылында «Мәдинә» кафесында дәвам итте. Безне «Сабакташлар» җыры яңгыраган матур бүлмә каршы алды. Очрашуның тамадасы Лилия Сибгатуллина бәйрәмебезгә матур төсмерләр өстәде. Ул, моңлы, серле тавышы белән җырлар сузды, төрле халык биюләре костюмнарын киертеп егетләребезне биетте, төрле уеннар белән аралаштырып, мәҗлесне югары дәрәҗәдә алып барды. Мул сыйлы табын артында мәктәп елларының янә күңелле, матур хатирәләрен яңарттык, кызыклы-шаян мизгелләрен искә төшердек.



Мәктәп елларында һәр кичәнең бизгә булган җырчыларыбыз Гыйбадуллина Гөлнур, Зыятдинова Фәридә, Зәбихуллина Резедәләрнең җырларын тыңладык. Җирле шагыйрә, сабакташыбыз Гайнетдинова Резедә сүзләренә Ренат Шаһидуллин иҗат иткән бүгенге көндә бик популяр булган «Сары розалар» җыры һәркем күңеленә хуш килде.

Төшләремдә бүләк иттең миңа
Матур гөлләр, сары розалар.
Сары төсләр сагыш билгесе бит
Үзәгемне өзеп алалар.

Һәркөн иртән күрәм бу төшемне
Кочагында сары розалар.
Ә күзләрең кара бөрлегәндәй
Гел елмаеп миңа багалар.

Сузасын син миңа кулларыңны
Бирергә дип чәчәк бәйләмен.
Белмисеңме сары розаларның
Чәнечкеле гөлләр булганын.

Йөзләрдән елмаю китмәде, истәлек-хатирәләр белән үрелеп барган очрашуыбыз озак сәгатьләргә сузылды, күңелләрдә матур тәэсирләр калдырды. Саубуллашканда киләсе очрашуны озакка сузмаска теләп таралыштык. Шушындый дус-тату сабакташларым, күңел түрендә сакланган истәлекләр барында мәктәп еллары безнең күңелләрдә озак сакланыр әле.

Сабакташларым арасыннан олы начальниклар, югары дәрәҗәле җитәкчеләр, зур «бизнесменнар» чыкмаса да, бер җилкуар да юк. Һәрберсе – белемле, үз һөнәрләренең остазлары, яраткан әни, әти, әби, бабай. Һәрчак ярдәм кулын сузарга әзер булган сабакташларым – төзегән тормышлары, башкарган эшләре белән мактауларга лаек кешеләр.

Тормыш мәшәкатьләре бетәрлек түгел, гомерләр бигрәк тә кыска бит, ярый әле очраштык, сөйләштек, биш елга яшәреп киткәндәй булдык. Очрашуны оештыру өчен алдан йөргән сабакташларга (Зыятдинова Фәридә, Гыйбадуллина Гөлнур, Мингалиева Сания) рәхмәтләрнең иң олысы. Киләчәктә дә очрашулар насыйп булсын, иң мөһиме, үзебез исән-сау, илләребез тыныч булсын.

*Роза Хәмидуллина,*
*Норлат мәктәбенең 1979 ел чыгарылыш укучысы.*